**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.02. 2022 № 112

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы уставы нигезендә, 2022 елның 28 гыйнварындагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2022 елның 28 гыйнварындагы бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күңгәр авыл җирлегенә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының « Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru).
3. Әтнә муниципаль районының Күңгәр авыл җирлеге советына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күңгәр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре буенча 2013 елның 03 июнендәге 59 номерлы, элегрәк кабул ителгән карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә

муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов